Татарстан Республикасы “Лениногорск муниципаль районы”
Лениногорск шәһәре 4 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе

**Балачагында алган тәрбия чәч агарганчы бергә булыр**

**(**Ризаэтдин Фәхреддин**)**

“Чишмә”иҗат берләшмәсе ,“Әдәби мирас” музее әгъзалары һәм укучыларның берләштерелгән утырышы

**Утырышның барышы:**

**Укытучы:**

- Исәнмесез, укучылар, хөрмәтле “Чишмә” иҗади берләшмәсе әгъзалары. Кешелек җәмгыятен һәрвакыт борчып килгән әхлак мәсьәләләре – намус, гаделлек, җирдә дөрес итеп яшәү, эти-әни һәм Ватан алдындагы изге бурычны үтәү кебек төшенчәләр мәңгелек . Без бүген бөек галим Ризаэтдин Фәхреддиннең шул темага караган эшләре белән танышырбыз, күзәтү ясарбыз. ,,Шәкертләрне гыйлем белән тәрбияләү, изге шәригатьтә аңлатылган күркәм холыклар белән таныштыру һәм гадәтләндерү,”- дип язган Ризаэтдин Фәхреддин.

Бүген утырышка “Чишмә” иҗади берләшмәсе әгъзалары да килде.Без аларны күрүебезгә бик шат, һәрвакыт көтеп алабыз. Безгә утырышка Әлфия Сөләйманова, Мәһәрша Сәлах кызы Вәлиуллова ,Рәсим Хәбибуллалар килде.

Хәзер сүзне “Чишмә” иҗади берләшмәсе җитәкчесе Таһир Ярулла улы Шәмсуаровка бирәбез. Таһир абый үзе килә алмау сәбәпле , ЗУМнан видеосәламләү карап үтик. **(видео)**

- Ризаэддин Фәхреддинның барлык китаплары, бигрәк тә тәрбия-тәгьлим юнәлешләрендәгеләре, халык арасында бик танылган һәм киң таралган. Бу китаплар нәшриятта кабат-кабат басылып чыккан. Тәрбия китапларында пакьлек, төрле авырулар, ашау-эчу кагыйдәләре, өс һәм аяк киемнәре һәм башкалар хакында мәгълүмат һәм киңәшләр китерелә. Бу китапларда тәрбия фәненең нигезләре кертелгән, аларның бар кыйммәте — аңлаешлы итеп язу һәм кеше тәрбияләүнең җаваплы бер эш икәнен исбат итү.“Балачагында алган тәрбия чәч агарганчы бергә булыр. Бала чакта алынган тәрбияне соңыннан бөтен дөнья халкы үзгәртә алмас, “-ди Ризаэддин Фәхреддин Сез бу сүзләрне ничек аңлыйсыз?

- Сүзне “Чишмә” иҗади берләшмәсе әгъзасы Рәсим Хәбибуллага бирәбез.Ул "Мөхәммәдия" мәдрәсәсен тәмамлаган публицист. "Корьән Һәм сөннәт кушканча гыйбадәт", "Җәннәткә мәҗбүриләү юк", "Хәятел ислам вә бәянел хак" китаплары авторы.

**Рәсим Хәбибулла:** Ризаэддин Фәхреддинн баланы туган көненнән башлап тәрбия итәргә кирәк, ди. Мәктәпкәчә һәм мәктәп яшендәге балаларны тәрбияләү алымнарын да җентекләп өйрәтә ул. Балалар белән тыныч, салмак тавыш белән сөйләшергә, аңлатырга, кыйнамаска һәм башка төрле физик

җәзалаулар белән эш итмәскә кирәклеген әйтә. Яшүсмерләргә ялкау кешеләр белән дуслашмаска киңәш бирә. Китапта каралган мәсьәләләрдә зур һәм мәшһүр зыялы затларның фикерләрен, сүзләрен китерә. “Ялкаулыктан биздерәчәк, тырышлыкны яраттырачак, милләтне сөю, күңел сафландыру хакында  булган мәсәлләрне, хайваннар авызыннан сөйләнгән хикәяләрне, авыру вә  сәламәтлек сәбәпләрен, мәҗлес вә әңгәмә әдәпләрен гаять ләззәтле һәм дә  балаларга яратырлык итеп риваять итәр. Мондый балаларга - яхшы тәрбия алган  балалар, вә мондый тәрбиягә яхшы тәрбия диярләр,” - ди галим.

**Укытучы:** Ризаэддин    Фәхреддин укытучы булып гомер буе  эшләмәсә дә,тәрбия темасына караган мәкаләләр күп яза. Ул бу эшләре белән кайларда чыгыш ясаган?

**1 нче укучы:**Риэаэтдин хәлфә укытучы булып гомере буе эшләмәсә дә, тәгълим-тәрбия эшләре белән һәрдаим кызыксынган. Ун ел буе баш мөхәррир булып эшләгән «Шура» журналы идарәсендә мәгариф эшләренең һәр ягы тулысынча чагылдырыла. Шулар эчендә халык арасында аң-белем тарату да, ысул җәдиднең нәрсә икәнен аңлату да, мәктәпләр, мәдрәсәләр, китапханәләр, китаплар, борынгы кулъязмалар, уку әсбаплары, укытучылар җитештерү, дөньяви-фәнни дәресләрне кыю рәвештә программага кертү һәм башкалар.

**2 нче укучы** “Тәрбияләрнең беренчесе - аналардан һәм аналык хезмәтендә булган кешеләрдән; икенчесе - укытучылардан; өченчесе - укытучылардан, укылачак китаплардан һәм газеталардан, дуслардан һәм яхшы мөгамәләдә булачак  затлардан өйрәнелер,- ди Ризаэтдин хәлфә . Чыннан да без тәрбияне иң беренче кадерле әниләребездән алабыз. Аларның әйткән һәр сүзе алтын бәясенә тора. Беренче җырлаган бишек җырлары да үзе бер тәрбия чарасы булып тора.

**Укытучы:** сүзне “Чишмә” иҗади берләшмәсе әгъзасы Мәһәрша Сәлах кызы Вәлиуллова бирәбез. Ул- әниләр темасын киң чагылдырган шагыйрә.

**Мәһәрша Сәлах кызы Вәлиуллова:** Чыннан да без тәрбияне иң беренче кадерле әниләребездән алабыз. Аларның әйткән һәр сүзе алтын бәясенә тора, дигән сүзләр белән мин ризалашмыйча булдыра алмыйм.Үзем олы яшьтә булсам да, һәрвакыт әниемне искә төшерәм, сагыну , ярату хисе һич тә югалмый.

***Инәйгә***

Капка төпләренә чыгар идең
Әти белән икәү бергәләп.
Назлы кочагыңа алдың мине
Битләремнән сыйпап, иркәләп.
Юксынулар еллар узган саен
Тик көчәя бара, сүрелми.
Өстәлләр мул, табын тулы ризык,
Синең кыстыбыйлар күренми...

Сезнең арада да  шигырь тибрәтүчеләр бар , дип ишеттем.Әйдәгез әле тыңлап карыйк.

**Укытучы:** әниләре,туган яклары турында иҗат иткән шигырьләрен  безгә Ләлә Сабитова, Динар Ситдыйков,Эльвина Шәриповалар укып күрсәтер.

**Укытучы**: әниегез сезгә нинди бишек җырлары җырлаган икән? Мин сезгә шуларны белешеп килергә әйткән идем.

**Знче укучы**:әниемнән  миңа җырлаган бишек җырын җырлап күрсәтүен сорадым. Ул болай яңгырый:

Әлли- бәлли  бәпкәсе,

Кая киткән әнкәсе?

Каенлыкка җиләккә

Минем улыма бүләккә

Монда җиләк күп икән

Аю-бүре юк икән

Әлли-бәлли бәү иткән

Улым йоклап та киткән

Йокла улым күз нурым

Күзнурым, йолдызым

Әлли-бәлли бәү

Әлли-бәлли бәү.

**Укытучы** : күрәсезме, әниләрегез сезгә нинди матур сүзләр белән эндәшкәннәр: күз нурым, йолдызым, улым, кызым дигәннәр.Әниләрегезгә игътибарлы булыгыз, әйткән сүзләрен тыңлагыз, дигән Р.Фәхреддин.

Татар халык әйтем-мәкальләрендә дә шуның турында күп әйтелә.

**4 нче укучы:** әхлакый белем һәм тәрбия бирүдә татар халык авыз иҗатының да әһәмияте зур дип уйлыйм. Әти-әнием кабатлый торган әйтем-мәкальләр минем холкым формалашуда зур урын алып торалар :

Ата-ана гаебен тикшерү бала эше түгел.

Әни суккан авыртмый.

Үзең бел – ата-анаңа киңәш ит.

Аюда аппагым, керпе дә йомшагым ди.

Ир егеткә җитмеш төрле һөнәр дә аз.

Акыллы әйтер юл куйдым.

Ахмак әйтер уздым.

Җылы сүз җан эретә.

**Укытучы:** җәмгыять бер урында гына тормый, үсә, үзгәрә. Күп кенә кыйммәтләр югалган чорда да, аның "Тәрбияле бала" китабы хәзерге буын балаларына да төпле киңәшләрбирә.

**5 нче укучы**: "Егетләр, кызлар колагына киңәшләр" дигән бүлекләрне мин кабат – кабат укыйм. "Әй хөрмәтле кызлар! Вә әй гыйззәтле карендәшләр! Сезгә мәгълүмдер ки: холкы гүзәл булган кыз бала – бөтен гаиләсе өчен олуг байлык вә бәхеттер. Карендәшләре өчен кыйммәтле хәзинәдер. Үскәннең соңында бер иргә ихлас белән ярдәмче вә иптәштер. Моның кебек кыз балалар белән мактанырлар вә моның кебек кыз балаларны иң түбән халыклардан башлап, иң бөек адәмнәргә кадәр, барысы да мактарлар. Укыган вә холкын тәрбияләгән кыз – алтыннан да кыйммәтле вә энҗедән дә кадерле байлыктыр ки: моның кебек кызларның күләгәләре иң ерак карендәш вә белешләргә кадәр ирешер. Карендәш кабилә арасында гына түгел, холыклы

вә гүзәл тәрбияле кешеләр беләң милләт вә бөтен дөнья халкы мактаныр.", - дигән ул .

**Укытучы**:Ул һәр кыз баланың өстәл китабы булса иде! "Балаларга үгет-нәсыйхәт"дигән китабында сүз нәрсә турында бара?

**6 нчы укучы**: Ризаэддин бине Фәхреддин үзенең "Балаларга үгет-нәсыйхәт"дигән китабында әдәплелек, әхлак, күркәмлек сыйфатларын тәрбияләү турында болай яза: "Әдәпле кешеләрне Аллаһы Тәгалә сөяр, халык та сөяр, исеме үзеннән соңнарга калыр, бәхетле булыр, - ди ул. -Әдәпсез кешеләр исә - халык күзендә дошман күренер, исеме сөйләнелмәс, дөньядан үткәндә һәркем рәхәтләнер дә, бер-ике сәгатьтән соң, тәмам онытылыр, гүя дөньяга килмәгән кебек саналыр," -дип дәвам итә.

**7 нче укучы** : тәрбия эшенең камиллеккә ирешү икәнен күрсәтеп, Р. Фәхреддин түбәндәге сүзләрне китерә: «Тәрбиясе булмаган җирдә гүзәл ашлык җитешмәгән кебек, тиешле тәрбия бирелмәгәнлектән, гүзәл кеше дә җитешмәс».

"Ялкаулыктан биздерәчәк, тырышлыкны яраттырачак, милләтне сөю, күңел сафландыру хакында булган мәсәлләрне, хайваннар авызыннан сөйләнгән хикәяләрне, авыру вә сәламәтлек сәбәпләрен, мәҗлес вә әңгәмә әдәпләрен гаять ләззәтле һәм дә балаларга яратырлык итеп риваять итәр. Мондый балаларга - яхшы тәрбия алган балалар, вә мондый тәрбиягә яхшы тәрбия диярләр",- дигән Р.Фәхретдин.

**Укытучы:** сүзне "Чишмә" иҗади берләшмәсе әгъзасы Әлфия Сөләймановага бирәбез.Соңгы елларда ул туган тел, әхлак темасына күп кенә шигырьләр иҗат итте.

**Әлфия Сөләйманова:** Р. Фәхреддин : «Тәрбиясе булмаган җирдә гүзәл ашлык җитешмәгән кебек, тиешле тәрбия бирелмәгәнлектән, гүзәл кеше дә җитешмәс».Чыннан да шулай ул, укучылар. Кеше кеше булып калсын өчен, ул дөньяда гүзәл эшләр генә эшләп калдырырга тиеш.Мин Шөгер ягыннан. Безнең яктан бөек шәхесләр чыккан, алар дөрес тәрбия алып үскәнгә күрә, шундый булганнар дип уйлый мин.

“Шөгер” дигән шигыремдә мин алар турында яздым:

...Галимнәрең Энгель, Индусларың,
Мәктәбеңдә белем алганнар.
Академик булып үсүләренә,
Горурланыр бик күп балалар!!!

Шөгер дисәң, язылادыр шигырь,
Шөгер дисәң туа яңа җыр...
Талантлы яшьләрең яшәгәндә,
Хәзинәләр иле яшәрер,
Төбәгебез ягы ямьләнер!!!

**Укытучы**: соңгы елларда әхлаксызлык күренеше тормышыбызның күп ягына үтеп керде. Мондый шартларда Р.Фәхреддинн китапларының яшь буынга әхлак тәрбиясе бирүдә әһәмияте гаять зур. Аның безгә, яңа буынга, әйтеп калдырган гыйбрәтле сүзләрен искә төшерик, хәтердә калдырыйк.(Укучылар укый)

* Бәрәкәтле адәм шул кешедер: сүзенә караганда эше күп вә тышына караганда эче яхшы.

*Дөньяда иң авыр нәрсә — ризык аз вә гакыл күп булып, икесе бергә җыелудыр.

* Якын карендәшләреңне бозык кешеләрдән саклавың кебек, китапларыңны да тиешле булмаган кешеләрдән сакла.

* Ачу килү изгелекләрне оныттыра.

* Тиешле булмаган кешене мактау вә яманлау — сазлыкка өй салу мисалында.

* Күп фикерлә, аз сөйлә.

* Күңелне үзенә тартучы нәрсә — кешенең яхшы холкы белән яхшы гадәтләредер.

* Сүзләрнең кыйммәтлесе — заман үтү белән онытылмый торганы.

*Балаларга калдыра торган мирасларның иң кыйммәтлесе — дин өйрәтеп калдыру.

*Гакыллы дус — арыган вакытта утырып бара торган арба.

*Гакыллы кешенең йөге — башында, ахмак кешенең йөге — аркасында.
*Эшләп аруга караганда тик торып ару авыр.
*Әйткән сүз, үткән гомер — агып киткән су мисалында.
*Тугрылык — максатка бара торган юлларның һәм кыскасы, һәм яхшысы.
*Бу дөньядагы кайгылар, авырлыклар — адәм балаларының имтихан бирүе.
*Сәламәтлегеңне саклыйсың килсә, һәр эшеңдә сак бул.

**Укытучы:** укучылар, йомгаклап шуны әйтәсе килә:халкыбызның акыл иясе Риза Фәхретдиннең зирәк фикеренә ешрак колак салсак иде. "Бала чакта алган тәрбияне соңрак бөтен дөнья халкы да үзгәртә алмас", – дип кисәтә ул. Ризаэтин Фәхреддинның барлык китаплары, бигрәк тә тәрбия-тәгьлим юнәлешләрендәгеләре, халык арасында бик танылган һәм киң таралган. Бу китаплар нәшриятта кабат-кабат басылып чыккан. Тәрбия китапларында пакьлек, төрле авырулар, ашау-эчу кагыйдәләре, өс һәм аяк киемнәре һәм башкалар хакында мәгълүмат һәм киңәшләр китерелә. Бу китапларда тәрбия фәненең нигезләре кертелгән, аларның бар кыйммәте — аңлаешлы итеп язу һәм кеше тәрбияләүнең җаваплы бер эш икәне исбат ителә.

Ризаэддин Фәхреддин хезмәтләрен, китапларын куллану — киләчәк буынны шәхес итеп тәрбияләүдә отышлы чара.

Укучылар, “Чишмә” иҗади берләшмәсе әгъзалары белән берлектә уздырылган утырышыбыз бүгенгә тәмам.Кунакларыбызга зур рәхмәт, аларга иҗади уңышлар телибез.Мондый утырышлар әле алда да булачак, сау булыгыз.